СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гагарина, д.29, с.Куюк-Ерыкса,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Гагарин ур., 29 нче йорт, Көек-Ерыкса авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-66-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Решение

« 13» апрель, 2026 ел — № 2-5

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында " 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек Ерыкса авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек Ерыкса авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын таныргa:

- 2021 елның 10 июнендәге 2-8 номерлы "Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү турында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында”;

- 2022 елның 15 августындагы 3-18 номерлы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" ;

- 2017 елның 25 августындагы 1-22 номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының " Көек Ерыкса авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне "Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында”;

2. Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый

мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районының Көек Ерыкса авыл җирлеге башлыгы Шәйхетдинов Ф.Р.ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көек Ерыкса авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе /Ф.Р.Шәйхетдинов/